**«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Куйбышев Затоны шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**2020 елның 15 июне** **№151**

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Куйбышев Затоны шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында

«2020 елдаРоссия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларының үтәлү үзенчәлекләрен билгеләү турында» 2019 елның 12 ноябрендәге 367-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Куйбышев Затоны шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Куйбышев Затоны шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советының 2012 елның 14 сентябрендәге 50 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Куйбышев тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставының 93 статьясындагы 3 пунктының, 93 статьясындагы 5 пунктының (бюджет үтәлеше турында еллык хисапка бәяләмәләр әзерләү сроклары өлешендә) 2021 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдә булуын туктатып торырга.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

- ТР, Кама Тамагы муниципаль районы, Куйбышев Затоны шәһәр тибындагы поселогы, Ульяновск шоссесы 12;
- ТР, Кама Тамагы муниципаль районы, Куйбышев Затоны шәһәр тибындагы поселогы, Куйбышев ур., 2А;
- ТР, Кама Тамагы муниципаль районы, Куйбышев Затоны, Парк ур.,

шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**«Татарстан Республикасы Кама Тамагы**
**муниципаль районының Куйбышев**
**Затоны шәһәр тибындагы поселогы»**
**муниципаль берәмлеге башлыгы,**
**«Татарстан Республикасы Кама Тамагы**
**муниципаль районының Куйбышев**
**Затоны шәһәр тибындагы поселогы»**
**муниципаль берәмлеге Советы рәисе** **Н.Б. Ефимов**